**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ФОМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ФОМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Фома ав. **КАРАР**

**14 октябрь 2022 ел** **№ 7**

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Нурлат муниципаль районының Фомкино авылы җирлегенә керүче Фома авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елның 25 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Фома авылы, Школьная урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылының Спутник урамында 1-29нчы йортларда, Чапаев урамындагы 1-85нче йортларда, Речная урамында 1-46нчы йортларда, К. Маркс урамы буенча 2-90нчы йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2022 елның 26 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Фома авылы, Школьная урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылының Школьная урамында 1-53нче йортларда, Совет урамындагы 1-45нче йортларда, Дружба урамында 2-82нче йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2022 елның 27 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Фома авылы, Школьная урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылының Тукай урамында 1-57нче йортларда, Молодежная урамындагы 1-7 нче йортларда, Гагарина урамында 1-37нче йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. Халык җыенын үткәрү өчен Фомкино авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.
5. Халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты белән тәэмин ителә.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәүче балигъ булган, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту һәм грунт катыш таш җәю;
- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү
- янгын сүндерү җиһазлары сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге башлыгының «Нурлат муниципаль районы Фома авылында халык җыенын билгеләү турында " 30.09.2022 ел, № 6 карары үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фомкино авылындагы мәгълүмат стендларында, гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов